ГЛАВА ЧЕРНЫШЕВСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЫСОКОГОРСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
422710, Республика Татарстан, Высокогорский район,,
д.Чернышевка, ул. Клубная, 1

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БИЕКТАУ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ЧЕРНЫШЕВКА АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ
422710, Татарстан Республикасы, Биектау районы,
Чернышевка авылы, Клуб ур.,1

Тел./факс: +7(84365) 73-5-05, e-mail: Chern.Vsg@tatar.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**30 октябрь, 2019 ел** **№ 3**

## Гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча Биектау муниципаль районы Чернышевка авыл җирлегенең Каймар, Шушара торак пунктларында гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Биектау муниципаль районы Чернышевка авыл җирлеге Уставының 22 статьясы һәм 2019 елның 21 октябрендәге 196 номерлы «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Чернышевка авыл җирлеге составына керә торган торак пунктларда гражданнар җыенын әзерләү һәм уздыру тәртибе турында нигезләмәне раслау хакында», Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Чернышевка авыл җирлеге муниципаль берәмлеге башлыгы урынбасары

**КАРАР БИРДЕ:**

1.Үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләргә:

1.1. 2019 елның 08 ноябрендә 11 сәгать 00 гә Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының Шушар авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының : Шушар авылы, Юбилей урамы, 46 йорт янында .

1.2. 2019 елның 08 ноябрендә 13 сәгать 00 гә Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының Каймар авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының:Каймар авылы, Үзәк урамы,52 йорт янында.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган түбәндәге сорауны расларга:

2.1.Шушар торак пунктында: «2020 елда яшәү урыны буенча теркәлгән һәм Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Чернышевка авыл җирлегенең Шушар торак пункты территориясендә даими яшәүче һәр балигъ булган кешедән 500 сум күләмендә үзара салым кертергә, һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә, түбәндәге эшләрне башкаруга:

- Шушары авылында чишмәне төзекләндерү;

- Чернышевка авылы җирләнгән урынга керү юлын төзекләндерү, Күмү урыннарын коймалау;

юллау белән килешәсезме?

«ӘЙЕ» «КАРШЫ».

2.2. Каймар торак пунктында: «2020 елда яшәү урыны буенча теркәлгән һәм

Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Чернышевка авыл җирлегенең Каймар торак пункты территориясендә даими яшәүче һәр балигъ булган кешедән 500 сум күләмендә үзара салым кертергә, һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә, түбәндәге эшләрне башкаруга:

- вак таш сатып алу һәм Каймар торак пунктында посёлок эчендәге юлларны ремонтлауга;

- Каймар авылында балалар мәйданчыгы сатып алу.

юллау белән килешәсезме?

«ӘЙЕ» «КАРШЫ».

3. Әлеге карарны мәгълүмати стендларда һәм җирлекнең рәсми сайтында кабул ителгән көненнән алып 10 көн эчендә урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

4. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Совет Рәисе
Авыл җирлеге башлыгы О.А.Маланин